СОВЕТ СОКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.38, с. Соколка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422181

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКОЛКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәб ур., 38 нче йорт, Соколка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422181

тел.(факс): (85563) 3-82-05; e-mail: Sokol.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР
14.12.2018 №4-37

## Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советының 2017 елның 16 декабрендә кабул ителгән «2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар планлы чорына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге бюджеты турында» 1-27 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына бюджеты турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Мамадыш муниципаль районы Советы карарлары, Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советының 2017 елның 16 декабрендә кабул ителгән «2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар планлы чорына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге бюджеты турында» 1-27 номерлы карары, 2018 елның 18 июнендәге №2-32 карарлары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджет Кодекслары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1. Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советының 2017 елның 16 декабрендә кабул ителгән «2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар планлы чорына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге бюджеты турында» 1-27 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1 Статья

2018 елга Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 4380,5 мең сум күләмендә;

2) Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының фаразлана торган гомуми күләмен 4774,4 мең сум күләмендә.

3) Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 393,9 мең сум күләмендә.

2. Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын 2019 һәм 2020 еллар план чорына түбәндәгечә билгеләргә:

1) 2019 елга Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 2761,1 мең сум һәм 2020 елга 2792,5 мең сум күләмендә;
2) Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2019 елга 2761,1 мең сум күләмендә; һәм 2020 елга 2792,5 мең сум күләмендә;
3.Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 статья

1. 2019 елның 1 гыйнварына Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиге 0 мең сум күләмендә.
2. 2020 елның 1 гыйнварына Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиге 0 мең сум күләмендә.
3. 2021 елның 1 гыйнварына Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиге 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиге 0 мең сум күләмендә расларга.
4. Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге муниципаль бурычының чикле күләмен расларга:
- 2018 елда - 0 мең сум күләмендә;
- 2019 елда - 0 мең сум күләмендә;
- 2020 елда - 0 мең сум күләмендә.

3 статья

Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге бюджетында 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына керемнәрнең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 60.1 статьясындагы 2 пункты нигезендә 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Мамадыш муниципаль районының бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативларын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

5 статья

1. Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге Карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге Карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

6 статья

1. Соколка авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге чыгымнарының ведомство структурасын 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Соколка авыл җирлегенең 2018 елга бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 0 мең сум күләмендә, 2019 елга 0 мең сум һәм 2020 елга 0 мең сум күләмендә расларга.

7 статья

Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге бюджетында Мамадыш муниципаль районы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар 2018 елда 3674 мең сум, 2019 елда 2261,1 мең сум һәм 2020 елда 2285,5 мең сум күләмендә әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

8 статья

1. Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары 2018 елда һәм 2019 һәм 2020 елларның планлы чорында муниципаль хезмәткәрләр һәм бюджет өлкәсендәге башка оешмалар хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз.

9 статья

Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге бюджеты акчаларының 2018 елның 1 гыйнварына калган өлеше, Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге исеменнән төзелгән сатып алуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә контрактлар буенча 2017 елда шушы муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле контрактларны үтәүгә, хезмәтләр күрсәтүгә контрактлар буенча төзелгән контрактлар өчен түләүгә тотылган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә, 2018 елда әлеге максатларга бюджет ассигнованиеләре артуга тиешле карар кабул ителгән очракта җибәрелә дип билгеләргә.

10 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләр башкара.

11 статья

Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

12 статья

Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Соколка
авыл җирлеге башлыгы А.Г. Рахимзянов